КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 13 апрель г.Казань № 394

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2025 – 2027 елларда өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт тәрбияләү системасын гамәлгә ашыру чаралары турында» 2021 ел, 13 февраль, 77 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 24 декабрь, 1278 нче, 2022 ел, 25 июль, 716 нчы, 2022 ел, 30 ноябрь, 1270 нче, 2023 ел, 21 март, 305 нче, 2023 ел, 2 июнь, 680 нче, 2024 ел, 29 март, 202 нче, 2024 ел, 30 май, 377 нче, 2024 ел, 4 декабрь, 1094 нче, 2024 ел, 21 декабрь, 1181 нче, 2025 ел, 16 апрель, 235 нче, 2026 ел, 28 гыйнвар, 54 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2025 – 2027 елларда юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга «Карау буенча ярдәмче» хезмәте күрсәтүгә бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта:

«шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 ел, 24 декабрь, 3012-б номерлы боерыгы белән расланган 2025 елда» сүзләрен «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2025 ел, 09 декабрь, 2878-б номерлы боерыгы белән расланган 2026 елда» сүзләренә алмаштырырга;

1.5 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре Вәкаләтле органга җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

5.5 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.11 пунктның икенче абзацында татар текстында «субсидияне ирекле рәвештә кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын ирекле рәвештә кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга;

7.3 пунктның беренче абзацында «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коммерциягә карамаган оешмалар «Социаль няня» хезмәте күрсәтү» пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2025 ел, 13 октябрь, 827 нче карары белән расланган «Коммерциягә карамаган оешмалар «Социаль няня» хезмәте күрсәтү» пилот проекты кысаларында коммерциягә карамаган оешмалар «Социаль няня» хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә чыгымнарны финанс белән тәэмин итү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү  тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта татар текстында «мәгълүмат» сүзеннән соң «субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре вәкаләтле органга җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

5.5 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

5.11 пунктның икенче абзацында татар текстында «субсидияне ирекле рәвештә кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын ирекле рәвештә кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга;

7.3 пунктның беренче абзацында «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин